ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт,
423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 7** **2020 ел 2 ноябрь**

Ютазы муниципаль районыДим-Тамак авыл җирлегенең Тарлау торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә кабул ителгән Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, К А Р А Р И Т Ә М:

1. 2020 елның 12 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы, Дым-Тамак авыл җирлеге, Тарлау авылында, Гафиятуллин урамы буенча 15 нче йорт каршында гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрергә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Тарлау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән, балачактан инвалид булган, I һәм II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

- Тарлау авылында зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- буаны чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Димтамак авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», www.yutaza.tatar.ru веб-адрес буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

"Дим-Тамак авыл җирлеге"
муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары Ф.М.Гарипов